| МИНИСТЕРСТВО<br>ТРУДА, ЗАНЯТОСТИ И<br>СОЦИАЛЬНОЙ ЗАЩИТЫ<br>РЕСПУБЛИКИ<br>ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ХЕЗМӘТ, ХАЛЫКНЫ ЭШ<br>БЕЛӘН ТӘЭМИН ИТҮ ҺӘМ<br>СОЦИАЛЬ ЯКЛАУ<br>МИНИСТРЛЫГЫ |
|---|---|---|

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

01.06.2021 г.Казань № 381

Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгында 2021 елның 22 июнендә 7744 номеры белән теркәлде

Халыкка социаль ярдәм күрсәтү өлкәсендә дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең аерым административ регламентларына үзгәрешләр кертү турында

Халыкка социаль ярдәм күрсәтү өлкәсендә дәүләт хезмәтләре күрсәтү эшен камилләштерү максатларында б о е р ы к б и р ә м:

Халыкка социаль ярдәм күрсәтү өлкәсендә дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең аерым административ регламентларына кертелә торган, кушымтада бирелгән үзгәрешләрне расларга.

Министр Э.Ә. Зарипова

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 2021 елның 01 июнендәге 381 номерлы боерыгы белән расланды

Халыкка социаль ярдәм күрсәтү өлкәсендә дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең аерым административ регламентларына кертелә торган үзгәрешләр

1. Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «Һәлак булган (үлгән) сугыш инвалидының, Бөек Ватан сугышында катнашучының һәм хәрби хәрәкәтләр ветеранының гаилә әгъзасы таныклыгын (таныклык дубликатын) бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2012 елның 05 июлендәге 513 номерлы боерыгы (Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 19.06.2014 №333, 12.04.2016 №200, 08.06.2017 №348, 07.05.2018 №347, 18.09.2018 №859, 13.05.2019 №362, 14.11.2019 №1022, 14.07.2020 №512, 02.10.2020 №690 боерыклары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) белән расланган Һәлак булган (үлгән) сугыш инвалидынын, Бөек Ватан сугышында катнашучының һәм хәрби хәрәкәтләр ветеранының гаилә әгъзасы таныклыгын (таныклык дубликатын) бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2.5 пунктта «Стандартка карата таләпләр эчтәлеге» графасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1) Әлеге Регламентка 1 нче кушымта нигезендә формада һәлак булган (үлгән) сугыш инвалиды, Бөек Ватан сугышында катнашучы һәм хәрби хәрәкәтләр ветераны гаилә әгъзасы таныклыгы (таныклык дубликаты) бирү турында гариза (алга таба – гариза);

2) мөрәҗәгать итүченең 3 х 4 см фотосы;

3) һәлак булган (үлгән) затның хәрби хезмәт үтүе яки хәрби хәрәкәтләрдә катнашуы турындагы документларның күчермәләре.

Әлеге Регламентның 1.2 пунктының икенче абзацында күрсәтелгән гражданнар өстәмә рәвештә түбәндәгеләрне тапшыра:

һәлак булган (үлгән) зат иждивениесендә тору фактын билгеләү турында суд карары күчермәсен.

Әлеге Регламентның 1.2 пунктының алтынчы абзацында күрсәтелгән гражданнар өстәмә рәвештә түбәндәгеләрне тапшыра:

чит ил дәүләтнең компетентлы органы тарафыннан бирелгән баланың тууын теркәү турында таныклык күчермәсен һәм аның нотариаль яктан расланган рус теленә тәрҗемәсен;

чит ил дәүләтенең компетентлы органы тарафыннан бирелгән вафат булуны теркәү турында таныклык күчермәсен һәм аның нотариаль яктан расланган рус теленә тәрҗемәсен;

өйләнешүне теркәү турында чит дәүләтнең компетентлы органы тарафыннан бирелгән таныклык күчермәсен һәм аның нотариаль яктан расланган рус теленә тәрҗемәсен;

чит ил дәүләте территориясендә бирелгән Россия Федерациясеннән читтә белем алу турында документ күчермәсен һәм гомуми белем бирү оешмасында белем ала торган 16 яшьтән олырак бала өчен әлеге документның нотариаль таныкланган рус теленә тәрҗемәсен.

Документлар һәм белешмәләр мөрәҗәгать итүче тарафыннан тиешле оешмаларда – турыдан-туры, шул исәптән, мондый мөмкинлек булган очракта, электрон рәвештә алына.

Мөрәҗәгать итүче гариза белән мөрәҗәгать иткәндә паспорт (аны алмаштыра торган документ) күрсәтә.

Мөрәҗәгать итүче тарафыннан вәкаләт бирелгән зат һәм мөрәҗәгать итүчеләрнең законлы вәкилләре өстәмә рәвештә мөрәҗәгать итүченең мәнфәгатьләрен яклау вәкаләтләрен раслый торган документларның күчермәләрен тапшыра.

Документларның күчермәләре, әгәр алар Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә таныкланмаган булса, төп нөсхәләре белән бергә күрсәтелә һәм Идарә (бүлек) белгече тарафыннан таныклана.

Гаризаны почта аша җибәргәндә аңа теркәлә торган документларның күчермәләре (шәхесне таныклый торган документ күчермәсеннән кала) Россия Федерациясе законнары нигезендә таныкланган булырга тиеш.

Дәүләт хезмәте күрсәтүдән файдалану өчен гариза бланкын мөрәҗәгать итүче Идарәгә (бүлеккә) шәхсән мөрәҗәгать иткәндә алырга мөмкин. Гариза бланкының электрон рәвеше Министрлыкның рәсми сайтында урнаштырылган.

Гариза һәм документлар мөрәҗәгать итүче тарафыннан кәгазьдә тапшырыла яисә, тапшыру турында белдереп, заказлы почта юлламасы белән җибәрелергә мөмкин.

Гариза һәм электрон документ формасындагы документлар Идарәгә (бүлеккә), «Интернет» челтәрен дә кертеп, гомуми файдаланудагы мәгълүмат-телекоммуникация челтәрләреннән файдаланып җибәрелергә мөмкин;

2.6 пунктта «Стандартка карата таләпләр эчтәлеге» графасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек каналлары аша вәкаләтле органнардан түбәндәге мәгълүматларны үз эченә алган документлар алына:

туендыручыны югалту уңаеннан пенсия алу хокукы турында;

бала тууны дәүләт теркәвенә алу турында;

өйләнешүне дәүләт теркәвенә алу турында;

вафат булуны дәүләт теркәвенә алу турында;

18 яше тулганчыга кадәр 18 яшьтән өлкәнрәк балага инвалидлык билгеләнүе турында;

23 яше тулмаган баланың көндезге уку формасы буенча белем бирү оешмаларында укуы турында.

Әлеге документлар мөрәҗәгать итүче тарафыннан турыдан-туры вәкаләтле оешмалардан алынырга мөмкин, шул исәптән, мондый мөмкинлек булганда, электрон формада да, һәм әлеге Регламентның 2.5 пунктында билгеләнгән документ-

ларны тапшыру өчен әлеге Регламентта каралган тәртиптә тапшырылырга мөмкин.

Мөрәҗәгать итүченең югарыда күрсәтелгән документларны тапшырмавы мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту өчен нигез була алмый.

Идарә (бүлек) мөрәҗәгать итүчедән түбәндәгеләрне таләп итәргә хокуклы түгел:

дәүләт хезмәте күрсәтүгә бәйле рәвештә барлыкка килә торган мөнәсәбәтләрне җайга сала торган норматив хокукый актларда тапшырылуы яки гамәлгә ашырылуы күздә тотылмаган документларны һәм мәгълүматны тапшыруны яки гамәлләр башкаруны;

210-ФЗ номерлы Федераль законның 7 статьясының 6 өлешендә каралган документлардан тыш, шул исәптән мөрәҗәгать итүче тарафыннан дәүләт хезмәте күрсәткән өчен түләү кертелүен раслый торган, Россия Федерациясе норматив хокукый актлары, Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары нигезендә дәүләт хезмәтләрен күрсәтүче органнар, башка дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм (яисә) дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнаша торган дәүләт органнарының яки җирле үзидарә органнарының ведомство буйсынуындагы оешмалары карамагында булган документлар һәм мәгълүмат тапшыруны;

210-ФЗ номерлы Федераль законның 7 статьясының 1 өлешендәге 4 пунктында каралган очраклардан тыш, дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән яисә дәүләт хезмәте күрсәтүдән беренче мәртәбә баш тартканда булмавы һәм (яки) төгәл булмавы турында күрсәтелмәгән документларны һәм мәгълүмат тапшыруны;

210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясының 1 өлешендәге 7.2 пункты нигезендә элегрәк электрон үрнәкләре таныкланган документларны һәм мәгълүматларны кәгазьдә тапшыруны, мондый документларга тамгалар кертү яки аларны бетерү дәүләт хезмәте күрсәтүнең кирәкле шарты булып торган очраклардан тыш һәм федераль законнарда билгеләнгән башка очраклардан тыш.»;

3.4.1 һәм 3.4.2 пунктларны киләсе редакциядә бәян итәргә:

«3.4.1. Идарә (бүлек) белгече вәкаләтле органнардан электрон рәвештә түбәндәгеләр турында мәгълүматлар ала:

вафат булуны дәүләт теркәвенә алу турында;

балалар тууын дәүләт теркәвенә алу турында.

3.4.2. Идарәдә (бүлектә) таныклык (таныклык дубликаты) бирү карарын кабул итүгә кирәкле мәгълүматлар булмаган очракта, Идарә (бүлек) белгече, шул исәптән электрон рәвештә дә, ведомствоара электрон хезмәттәшлек системасы ярдәмендә вәкаләтле органнарга түбәндәге белешмәләрне бирү турында рәсми мөрәҗәгатьләр җибәрә:

туендыручыны югалту уңаеннан пенсия алу хокукы турында;

бала тууны дәүләт теркәвенә алу турында;

өйләнешүне дәүләт теркәвенә алу турында белешмәләр;

вафат булуны дәүләт теркәвенә алу турында белешмәләр;

18 яше тулганчыга кадәр 18 яшьтән өлкәнрәк балага инвалидлык билгеләнүе турында;

23 яше тулмаган баланың көндезге уку формасы буенча белем бирү оешмаларында укуы турында.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура гариза кергән көндә башкарыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: электрон формада алынган мәгълүматлар, мәгълүмат бирү турында рәсми мөрәҗәгатьләр.»;

5.4 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5.4. Шикаять алынган көненнән соңгы эш көне узганчы теркәлергә тиеш.

Шикаятьне карап тикшерү чоры – теркәүгә алганнан соңгы 15 эш көне эчендә.

Дәүләт хезмәте күрсәтүче органның, дәүләт хезмәте күрсәтүче органдагы вазыйфаи затның мөрәҗәгать итүчедән документларны кабул итүдән баш тартуын яисә җибәрелгән хаталарны һәм ялгышларны төзәтүдән баш тартуына шикаять белдерелгәндә яисә мондый төзәтмәләр кертүнең билгеләнгән вакыты бозылган очракта, – аны теркәүгә алганнан соңгы биш эш көне эчендә.».

2. Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «Һәлак булган (вафат булган) хәрби хезмәткәрләрнең һәм кайбер федераль башкарма хакимият органнары хезмәткәрләренең гаилә әгъзаларына торак урыннан файдалану, торак урынны карап тоту, күпфатирлы йортта гомуми милекне капиталь ремонтлау өчен кертем түләү, коммуналь һәм башка төр хезмәтләр күрсәтү өчен түләү чыгымнарына бәйле рәвештә компенсация түләүләре билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2012 елның 28 маендагы 361 номерлы боерыгы (Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 19.06.2014 № 332, 25.09.2014 №528, 16.05.2016 №262, 08.06.2017 №348, 17.11.2017 №810, 15.05.2018 №365, 24.09.2018 №897, 07.05.2019 №322, 13.11.2019 №1001, 25.03.2020 №193, 13.07.2020 №503, 28.09.2020 №674 боерыклары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) белән расланган Һәлак булган (вафат булган) хәрби хезмәткәрләрнең һәм кайбер федераль башкарма хакимият органнары хезмәткәрләренең гаилә әгъзаларына торак урыннан файдалану, торак урынны карап тоту, күпфатирлы йортта гомуми милекне капиталь ремонтлау өчен кертем түләү, коммуналь һәм башка төр хезмәтләр күрсәтү өчен түләү чыгымнарына бәйле рәвештә компенсация түләүләре билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентында (алга таба – Регламент):

1.4 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.4. Дәүләт хезмәте «Республикасы матди ярдәм (компенсация түләүләре) үзәге» дәүләт казна учреждениесе (алга таба – Үзәк) тарафыннан мөрәҗәгать итүченең яшәгән урыны буенча Татарстан Республикасы муниципаль районында яисә шәһәр округында Үзәк бүлекчәсендә (алга таба – Үзәк бүлекчәсе) күрсәтелә.»;

2.5 пунктта «Стандартка карата таләпләр эчтәлеге» графасының дүртенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Һәлак булган (үлгән) хәрби хезмәткәрләрнең Россия Федерациясеннән читтә белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы оешмаларда көндезге формада белем алучы 23 яшькә кадәрге балалары өстәмә рәвештә чит ил дәүләте территориясендә бирелгән белем алу турында документның күчермәсен һәм аның нотариаль расланган рус теленә тәрҗемәсен тапшыра.»;

2.6 пунктта «Стандартка карата таләпләр эчтәлеге» графасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Ведомствоара багланыш каналлары буенча вәкаләтле органнардан түбәндәге белешмәләрне үз эченә алган документлар алына:

түләү чыгымнары капланырга тиешле торак урында яшәү урыны буенча теркәлгән гражданнар саны турында;

шәхси счетның иминият номеры турында;

18 яше тулганчы инвалидлык билгеләү факты турында – һәлак булган (үлгән) хәрби хезмәткәрләрнең 18 яше тулганчы инвалид булган, 18 яшьтән өлкәнрәк балалары өчен;

23 яше тулмаган баланың көндезге уку формасы буенча белем бирү оешмаларында укуы турында.

Әлеге документлар гариза бирүче тарафыннан турыдан-туры вәкаләтле оешмалардан алынырга мөмкин, шул исәптән, мондый мөмкинлек булганда, электрон формада да, һәм әлеге Регламентның 2.5 пунктында билгеләнгән документларны тапшыру өчен әлеге Регламентта каралган тәртиптә тапшырылырга мөмкин.

Мөрәҗәгать итүченең югарыда күрсәтелгән документларны тапшырмавы мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту өчен нигез була алмый.

Үзәк бүлекчәсе мөрәҗәгать итүчедән түбәндәгеләрне таләп итәргә хокуклы түгел:

дәүләт хезмәте күрсәтүгә бәйле рәвештә барлыкка килә торган мөнәсәбәтләрне җайга сала торган норматив хокукый актларда тапшырылуы яки гамәлгә ашырылуы күздә тотылмаган документларны һәм мәгълүматны тапшыруны яки гамәлләр башкаруны;

210-ФЗ номерлы Федераль законның 7 статьясының 6 өлешендә каралган документлардан тыш, шул исәптән мөрәҗәгать итүче тарафыннан дәүләт хезмәте күрсәткән өчен түләү кертелүен раслый торган, Россия Федерациясе норматив хокукый актлары, Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары нигезендә дәүләт хезмәтләрен күрсәтүче органнар, башка дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм (яисә) дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнаша торган дәүләт органнарының яки җирле үзидарә органнарының ведомство буйсынуындагы оешмалары карамагында булган документлар һәм мәгълүмат тапшыруны;

210-ФЗ номерлы Федераль законның 7 статьясының 1 өлешендәге 4 пунктында каралган очраклардан тыш, дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән яисә дәүләт хезмәте күрсәтүдән беренче мәртәбә баш тартканда булмавы һәм (яки) төгәл булмавы турында күрсәтелмәгән документларны һәм мәгълүмат тапшыруны;

210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясының 1 өлешендәге 7.2 пункты нигезендә элегрәк электрон үрнәкләре таныкланган документларны һәм мәгълүматларны кәгазьдә тапшыруны, мондый документларга тамгалар кертү яки аларны бетерү дәүләт хезмәте күрсәтүнең кирәкле шарты булып торган очраклардан тыш һәм федераль законнарда билгеләнгән башка очраклардан тыш.»;

3.4.2 пунктны киләсе редакциядә бәян итәргә:

«3.4.2. Компенсация билгеләү турында (билгеләүдән баш тарту турында) карар кабул итү өчен кирәкле белешмәләр Үзәк бүлекәсендә булмаганда, Үзәк бүлекчәсе белгече, шул исәптән электрон рәвештә дә, ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек системасы ярдәмендә вәкаләтле органнарга түбәндәге белешмәләрне бирү турында

рәсми мөрәҗәгатьләр җибәрә:

түләү чыгымнары капланырга тиешле торак урында яшәү урыны буенча теркәлгән гражданнар саны турында;

шәхси счетның иминият номеры турында;

18 яше тулганчы инвалидлык билгеләү факты турында – һәлак булган (үлгән) хәрби хезмәткәрләрнең 18 яше тулганчы инвалид булган, 18 яшьтән өлкәнрәк балалары өчен;

23 яше тулмаган баланың көндезге уку формасы буенча белем бирү оешмаларында укуы турында.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура гариза алынган көнне башкарыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: мәгълүмат бирү турында рәсми мөрәҗәгатьләр.»

3.8.1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.8.1. Үзәк бүлекчәсе белгече:

техник хатаны төзәтү турында гаризаны кабул итә һәм гражданнарның мөрәҗәгатьләрен теркәү журналында (2 нче кушымта) терки;

компенсация билгеләү (билгеләүдән баш тарту) турында үзгәртеп рәсмиләштерелгән карарны имзалау өчен Үзәк бүлекчәсе җитәкчесенә җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура гариза кергән көндә башкарыла.

Процедураның нәтиҗәсе: техник хатаны төзәтү турында кабул ителгән һәм теркәлгән гариза, Үзәк бүлекчәсе җитәкчесенә имзалау өчен юлланган компенсация билгеләү турында (билгеләүдән баш тарту турында) үзгәртеп рәсмиләштерелгән карар.»;

5.4 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5.4. Шикаять алынган көненнән соңгы эш көне узганчы теркәлергә тиеш.

Шикаятьне карап тикшерү чоры – теркәүгә алганнан соңгы 15 эш көне эчендә.

Дәүләт хезмәте күрсәтә торган органның (учреждениенең), дәүләт хезмәте күрсәтә торган органдагы вазыйфаи затның (учреждение хезмәткәренең) мөрәҗәгать итүчедән документларны кабул итүдән баш тартуына яисә җибәрелгән хаталарны һәм ялгышларны төзәтүдән баш тартуына шикаять белдерелгәндә яисә мондый төзәтмәләр кертүнең билгеләнгән чоры бозылганда, – аны теркәүгә алганнан соңгы биш эш көне эчендә.»;

Регламентка 3 нче кушымтаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Һәлак булган (вафат булган) хәрби хезмәткәрләрнең һәм кайбер федераль башкарма хакимият органнары хезмәткәрләренең гаилә әгъзаларына торак урыннан файдалану, торак урынны карап тоту, күпфатирлы йортта гомуми милекне капиталь ремонтлау өчен кертем түләү, коммуналь һәм башка төр хезмәтләр күрсәтү өчен түләү чыгымнарына бәйле рәвештә компенсация түләүләре билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең

административ регламентына 3 нче кушымта

«Матди ярдәм (компенсация түләүләре) республика үзәге» ДКУ №____ бүлекчәсе

______________________________________

муниципаль районында (шәһәр округында)

Торак урыннан файдалану, торак урынны карап тоту, күпфатирлы йортта гомуми милекне капиталь ремонтлау өчен кертем түләү, коммуналь һәм башка төр хезмәтләр күрсәтү өчен түләү чыгымнарына бәйле рәвештә компенсация түләүләре билгеләү турында «__» ____________ №_____ КАРАР

Мөрәҗәгать итүченең ФИА ______________________________________________
Мөрәҗәгать итүченең адресы ____________________________________________

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Һәлак булган (вафат булган) хәрби хезмәткәрләрнең һәм кайбер федераль башкарма хакимият органнары хезмәткәрләренең гаилә әгъзаларына торак урыннан файдалану, торак урынны карап тоту, күпфатирлы йортта гомуми милекне капиталь ремонтлау өчен кертем түләү, коммуналь һәм башка төр хезмәтләр күрсәтү өчен түләү чыгымнарына бәйле рәвештә компенсация түләүләре бирү турында» 2005 елның 2 августындагы 475 номерлы карары нигезендә торак урыннан файдалану, торак урынны карап тоту, күпфатирлы йортта гомуми милекне капиталь ремонтлау өчен кертем түләү, коммуналь һәм башка төр хезмәтләр күрсәтү өчен түләү чыгымнарына бәйле рәвештә компенсация түләүләре билгеләргә.

Түләү ысулы
№____________ счетка, бүлекчә ___________ Банк _________________________;
почта бүлеге____________________________________________________________

РМЯ(КТ)Ү бүлеге җитәкчесе ______________________________
Ф.И.А. имза
РМЯ(КТ)Ү бүлеге белгече _______________________________ М.У.
Ф.И.А. (имза)

Мөрәҗәгать итүчегә хәбәр итү ысулы:
Язмача __________________________________________
(почта адресына)
sms-хәбәр итеп ________________________
телефон номеры
_____________________________ электрон почтасы аша
Электрон почта адресы
РМЯ(КТ)Ү бүлеге белгече _______________________________ М.У.
(имза)

«Матди ярдәм (компенсация түләүләре) республика үзәге» ДКУ №___ бүлекчәсе

________________________________________
муниципаль районында (шәһәр округында)

торак урыннан файдалану, торак урынны карап тоту, күпфатирлы йортта гомуми милекне капиталь ремонтлау өчен кертем түләү, коммуналь һәм башка төр хезмәтләр күрсәтү өчен түләү чыгымнарына бәйле рәвештә компенсация түләүләре билгеләүдән баш тарту турында
«__»____________ №_____ КАРАР

Мөрәҗәгать итүченең ФИА ______________________________________________
Мөрәҗәгать итүченең адресы ____________________________________________
______________________________________________________________________

Торак урыннан файдалану, торак урынны карап тоту, күпфатирлы йортта гомуми милекне капиталь ремонтлау өчен кертем түләү, коммуналь һәм башка төр хезмәтләр күрсәтү өчен түләү чыгымнарына бәйле рәвештә компенсация түләүләре билгеләүдән баш тартырга.

Баш тарту сәбәбе: ______________________________________________________
______________________________________________________________________

Бүлек җитәкчесе ____________________ ___________________
(Ф.И.А.) (имза)

Мөһер урыны

Бүлек белгече ____________________ ___________________
(Ф.И.А.) (имза)

Мөрәҗәгать итүчегә хәбәр итү ысулы:

Язмача ___________________________________________
почта адресы буенча

sms-хәбәр итеп _______________________
телефон номеры

электрон почта буенча _______________________________
электрон почта адресы

бүлек белгече __________________ ______________
(Ф.И.А.) имза».

3. Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «Россия Федерациясе илкүләм гвардия гаскәрләрендә хезмәт узган һәм махсус полиция исемнәре булган хәрби хезмәткәрләрнең, Россия Федерациясе эчке эшләр органнары, җинаять-үтәтү системасы, Янгынга каршы дәүләт хезмәтенең янгынга каршы федераль хезмәт учреждениеләре, Россия Федерациясе таможня органнары хезмәткәрләренең туендыручысын югалткан гаилә әгъзаларыныкы булган индивидуаль торак йортларга ремонт уздыруга акчалата түләү билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2012 елның 08 августындагы 643 номерлы боерыгы (Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының

06.06.2014 №311, 04.05.2016 №230, 08.06.2017 №348, 07.05.2018 №347, 19.09.2018 №892, 23.04.2019 №297, 13.11.2019 №1001, 25.03.2020 №193, 14.07.2020 №511, 02.10.2020 №692 боерыклары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) белән расланган Россия Федерациясе илкүләм гвардия гаскәрләрендә хезмәт узган һәм махсус полиция исемнәре булган хәрби хезмәткәрләрнең, Россия Федерациясе эчке эшләр органнары, җинаять-үтәтү системасы, Янгынга каршы дәүләт хезмәтенең янгынга каршы федераль хезмәт учреждениеләре, Россия Федерациясе таможня органнары хезмәткәрләренең туендыручысын югалткан гаилә әгъзаларыныкы булган индивидуаль торак йортларга ремонт уздыруга акчалата түләү билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентында (алга таба – Регламент):

2.5 пунктта «Стандартка карата таләпләр эчтәлеге» графасының унөченче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Һәлак булган (үлгән) хәрби хезмәткәрләрнең Россия Федерациясеннән читтә белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы оешмаларда көндезге формада белем алучы 23 яшькә кадәрге балалары өстәмә рәвештә чит ил дәүләте территориясендә бирелгән белем алу турында документның күчермәсен һәм аның нотариаль расланган рус теленә тәрҗемәсен тапшыра.»;

2.6 пунктта «Стандартка карата таләпләр эчтәлеге» графасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Ведомствоара хезмәттәшлек каналлары буенча вәкаләтле органнардан түбәндәге документлар һәм белешмәләр алына:

техник паспорт күчермәсе (техник паспорт булмаган яисә торак йорт техник инвентарьлаштыру органнары урнашкан торак пункттан ерак булган очракта, – җирле үзидарә органы белешмәсе, торак йортның төзелгән елын күрсәтеп);

Күчемсез мөлкәтнең бердәм дәүләт реестрында хокукы теркәлмәгән торак урынга хокук билгели торган документлар турында белешмәләр;

мөрәҗәгать итүче белән аның даими яшәү урыны буенча теркәлгән затлар турында белешмәләр;

шәхси счетның иминият номеры турында белешмәләр;

18 яше тулганчы инвалидлык билгеләнү факты турында белешмәләр – 18 яшьтән өлкәнрәк инвалид балалар өчен;

23 яше тулмаган баланың көндезге уку формасы буенча белем бирү оешмаларында укуы турында.

Мөрәҗәгать итүче югарыда аталган белешмәләрне раслый торган документларны үз инициативасы белән дә тапшырырга хокуклы.

Әлеге документлар мөрәҗәгать итүче тарафыннан турыдан-туры вәкаләтле оешмалардан алынырга мөмкин, шул исәптән, мондый мөмкинлек булганда, электрон формада да, һәм әлеге Регламентның 2.5 пунктында билгеләнгән документларны тапшыру өчен әлеге Регламентта каралган тәртиптә тапшырылырга мөмкин.

Мөрәҗәгать итүченең югарыда күрсәтелгән документларны тапшырмавы мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту өчен нигез була алмый.

Идарә (бүлек) мөрәҗәгать итүчедән түбәндәгеләрне таләп итәргә хокуклы түгел:

дәүләт хезмәте күрсәтүгә бәйле рәвештә барлыкка килә торган мөнәсәбәтләрне җайга сала торган норматив хокукый актларда тапшырылуы яки гамәлгә ашырылуы

күздә тотылмаган документларны һәм мәгълүматны тапшыруны яки гамәлләр башкаруны;

210-ФЗ номерлы Федераль законның 7 статьясының 6 өлешендә каралган документлардан тыш, шул исәптән мөрәҗәгать итүче тарафыннан дәүләт хезмәте күрсәткән өчен түләү кертелүен раслый торган, Россия Федерациясе норматив хокукый актлары, Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары нигезендә дәүләт хезмәтләрен күрсәтүче органнар, башка дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм (яисә) дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнаша торган дәүләт органнарының яки җирле үзидарә органнарының ведомство буйсынуындагы оешмалары карамагында булган документлар һәм мәгълүмат тапшыруны;

210-ФЗ номерлы Федераль законның 7 статьясының 1 өлешендәге 4 пунктында каралган очраклардан тыш, дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән яисә дәүләт хезмәте күрсәтүдән беренче мәртәбә баш тартканда булмавы һәм (яки) төгәл булмавы турында күрсәтелмәгән документларны һәм мәгълүмат тапшыруны;

210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясының 1 өлешендәге 7.2 пункты нигезендә элегрәк электрон үрнәкләре таныкланган документларны һәм мәгълүматларны кәгазьдә тапшыруны, мондый документларга тамгалар кертү яки аларны бетерү дәүләт хезмәте күрсәтүнең кирәкле шарты булып торган очраклардан тыш һәм федераль законнарда билгеләнгән башка очраклардан тыш.»;

3.4.1 пунктны киләсе редакциядә бәян итәргә:

«3.4.1. Идарә (бүлек) белгече ведомствоара электрон хезмәттәшлек системасы ярдәмендә, шул исәптән электрон рәвештә дә, вәкаләтле органнарга түбәндәге документларны һәм белешмәләрне бирү турында рәсми мөрәҗәгатьләр җибәрә:

техник паспорт күчермәсен (техник паспорт булмаган яисә торак йорт техник инвентарьлаштыру органнары урнашкан торак пункттан ерак булган очракта, – җирле үзидарә органы белешмәсе, торак йортның төзелгән елын күрсәтеп);

Күчемсез мөлкәтнең бердәм дәүләт реестрында хокукы теркәлмәгән торак урынга хокук билгели торган документлар турында белешмәләрне;

мөрәҗәгать итүче белән аның даими яшәү урыны буенча теркәлгән затлар турында белешмәләрне;

шәхси счетның иминият номеры турында белешмәләрне;

18 яше тулганчы инвалидлык билгеләнү факты турында белешмәләрне – 18 яшьтән өлкәнрәк инвалид балалар өчен;

23 яше тулмаган баланың көндезге уку формасы буенча белем бирү оешмаларында укуы турында белешмәләрне.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура гариза алынган көнне башкарыла.

Процедураның нәтиҗәсе: документлар һәм мәгълүматлар бирү турында рәсми мөрәҗәгатьләр.»;

3.7.1 пунктны киләсе редакциядә бәян итәргә:

«3.7.1. Идарә (бүлек) белгече:

техник хата төзәтү турында гаризаны кабул итә һәм гражданнарның мөрәҗәгатьләрен теркәү журналында терки (әлеге Регламентның 4 нче кушымтасы);

түләү билгеләү (билгеләүдән баш тарту) турындагы карарны үзгәртеп рәсмиләштерә;

түләү билгеләү (билгеләүдән баш тарту) турында үзгәртеп рәсмиләштерелгән карарны имзалау өчен Идарә (бүлек) җитәкчесенә җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар гаризаны теркәгән вакыттан башлап бер эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: техник хатаны төзәтү турында кабул ителгән, теркәлгән гариза, Идарә (бүлек) җитәкчесенә имзалау өчен юлланган түләү билгеләү турында (билгеләүдән баш тарту турында) үзгәртеп рәсмиләштерелгән карар.»;

5.4 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5.4. Шикаять алынган көненнән соңгы эш көне узганчы теркәлергә тиеш.

Шикаятьне карап тикшерү чоры – аны теркәүгә алганнан соңгы 15 эш көне эчендә.

Дәүләт хезмәтен күрсәтүче органның, дәүләт хезмәтен күрсәтүче органдагы вазыйфаи затның мөрәҗәгать итүчедән документларны кабул итүдән баш тартуын яисә җибәрелгән хаталарны һәм ялгышларны төзәтүдән баш тартуын шикаять кылганда яисә мондый төзәтмәләр кертүнең билгеләнгән вакыты бозылган очракта, – аны теркәүгә алганнан соңгы биш эш көне эчендә.»;

Регламентка 5 нче кушымтаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Россия Федерациясе илкүләм гвардия гаскәрләрендә хезмәт узган һәм махсус полиция исемнәре булган хәрби хезмәткәрләрнең, Россия Федерациясе эчке эшләр органнары, җинаять-үтәү системасы, Янгынга каршы дәүләт хезмәтенең янгынга каршы федераль хезмәт учреждениеләре, Россия Федерациясе таможня органнары хезмәткәрләренең туендыручысын югалткан гаилә әгъзаларыныкы булган индивидуаль торак йортларга ремонт уздыруга акчалата түләү билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына 5 нче кушымта

____________________________________
(социаль яклау органы исеме)

Индивидуаль торак йортка ремонт уздыруга акчалата
түләү билгеләү турында «__» ____________
№_____КАРАР

Мөрәҗәгать итүченең ФИА ____________________________________
Мөрәҗәгать итүченең адресы ______________________________________
Индивидуаль торак йортка ремонт уздыруга акчалата түләү билгеләргә.
Түләү ысулы

№_____________ счетка, бүлекчә ____________ Банк ___________________________;
п/бүлеге _____________________________________

Идарә (бүлек) җитәкчесе ___________________________ ______________
(Ф.И.А.) (имза)

Мөһер урыны

Идарә (бүлек) белгече: __________________________ ___________________
(Ф.И.А.) (имза)

Мөрәҗәгать итүчегә хәбәр ителде:
Язмача _____________________________________________
почта адресы буенча
sms-хәбәр итеп _________________________
телефон номеры
электрон почта буенча _________________________________
электрон почта адресы
бүлек белгече ___________________ _______________
(Ф.И.А.) имза».

Индивидуаль торак йортка ремонт уздыруга акчалата
түләү билгеләүдән баш тарту турында
«______ »_______________ №___ КАРАР

Мөрәҗәгать итүченең ФИА ________________________________________________
Мөрәҗәгать итүченең адресы _______________________________________________
Индивидуаль торак йортка ремонт уздыруга акчалата түләү билгеләүдән баш тартырга.
Баш тарту сәбәбе: ________________________________________________________

Идарә (бүлек) җитәкчесе _________________ __________________________
(Ф.И.А.) (имза)

Мөһер урыны
Идарә (бүлек) белгече _________________ _____________________________
(Ф.И.А.) (имза)

Мөрәҗәгать итүчегә хәбәр ителде:
Язмача _____________________________________________
почта адресы буенча
sms-хәбәр итеп _________________________
телефон номеры
электрон почта буенча _________________________________
электрон почта адресы
бүлек белгече ___________________ _______________
(Ф.И.А.) имза».